## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Татар Мөшегесе торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

20 ноябрь 2025

№ 12

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Әтрәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Әтрәкле авыл җирлеге Татар Мөшегесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, МХОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, һәм МХОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Татар Мөшегесе торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (таш сатып алу, ташу, җәю, юлны ремонтлау өчен тимер торба сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлеге мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районы сайтында http://menzelinsk/tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы

А.М. Гыйльмуллин

ОГРН 1021605552136
Совет
АТРЯКЛИНСКОГО
сельского поселения
ИНН 1623002869